СОВЕТ БОЛЬШЕЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ЖӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 162**

Олы Яке авылы

**05 сентябрь 2024 ел**

**Физик затлар мөлкәтенә салым турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезенндә , Олы Җәке авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә физик затлар мөлкәтенә салымны билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) 0,1 процент:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 5 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннарга;

- хуҗалык корылмалары яисә корылмалары, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан;

2) 02, процент

- фатирларга, фатирлар өлешләренә, бүлмәләргә карата;

3) 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортлар өлешләре;

- тегәлләнмәгән төзелеш объектлары, әгәр мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса;

- составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) 1,2%:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) карата:

5) 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларын;

6) 2,5 процент салым салу объектларына карата, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;

7) 0,5 процент салым салуның башка объектларына карата.

3. Олы Җәке авыл җирлеге Советы карарларының көчен югалткан дип танырга:

- «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 137 номерлы;

- «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 137 номерлы Олы Җәке авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 01 июнендәге 178-1 номерлы;

- «Олы Җәке авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 12 ноябрендәге 6 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 137 номерлы (2016 елның 01 июнендәге 178-1 номерлы Большеякин авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 137 номерлы Олы Җәке авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 25 августындагы 122 номерлы (2016 елның 1 июнендәге 178-1 номерлы Большеякин авыл җирлегенең 2014 елның 1 ноябрендәге 178-1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне кертеп);

- «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 137 номерлы Олы Җәке авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 16 ноябрендәге 130 номерлы (2016 елның 1 июнендәге 178-1 номерлы Олы Кариле авыл җирлеге Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән, 2015елның 12 ноябрендәге 6 номерлы, №122, №2018 елның 25 августындагы 122);

- «Олы Җәке авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 ноябрендәге 170 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 декабрендәге 137 номерлы (2015 елның 01 июнендәге 178-1 номерлы Большеякин авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 декабрендәге 6 номерлы, 2018 елның 25 августындагы 130 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

4. Әлеге карарның 2 пунктының 4 пунктчасы 31.12.2027 ел буенча гамәлдә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның 2 пунктындагы 5 пунктчасының гамәлдә булуын 2028 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

6. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Яке авылы , Мәктәп урамы, 1 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт (мәдәният йорты бинасы), шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (www.zelodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ф.А.Фәйзуллина**